**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКАИ ТАТАРСТАН**
пер. Школьный, д.5,
д. Тойгузино, Менделеевский район,
Республика Татарстан, 423646

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Мәктәп тыкрыгы, 5 йорт,
Тойгуҗа авылы, Менделеев районы,
Татарстан Республикасы, 423646

Тел. (факс): (85549) 3-40-13
e-mail: Toyg.Men@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 20 маеннан №3

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
"Тойгуҗа авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегенең
генераль план проекты буенча
гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Тойгуҗа авыл җирлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгатьчелек фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында" 2018 елның 31 августындагы 74 номерлы нигезләмәгә таянып, Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР ИТӘ:

1.2022 елның 20 июнендә сәгать 16: 00 минутта Менделеевск районы, Тойгуҗа авылы, Мәктәп тыкрыгы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:

Сафин Р.А. – Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе;

Кудрина Г.Р. – Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге рәисе урынбасары

Хәбибрахимов Р. – Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге депутаты (килешү буенча)

3. 2022 нче елның 20 нче маеннан 19 нчы июненә кадәр Тойгуҗа авылы, Мәктәп тыкрыгы, 5 нче йорт адресы буенча Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге

башкарма комитеты бинасында «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты материалларының экспозициясен оештырырга.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә (җибәрелә): 423646, Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Тойгуҗа авылы, Мәктәп тыкрыгы, 5 нче йорт (Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы исеменә).

5. Әлеге карарны Тойгуҗа авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга. http://Mendeleevsk.tatar.ru.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Р.А. Сафин